РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ»

Переулок Больничный, дом 6,
пгт. Рыбная Слобода, 422650

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

«МӘГАРИФ БҮЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

Хастаханә тыкрыгы, 6 нчы йорт,
Балык Бистәсе штп., 422650

Тел.: (8-84361) 2-21-92, факс: (8-84361) 2-21-26. E-mail: sloboda.ege@rambler.ru, sloboda.filial@mail.ru

---

ПРИКАЗ **БОЕРЫК**

№ 705о/д «30 » октября 2018 г

О проведении муниципальной научно-практической конференции обучающихся «Әдәби мираслы Балык Бистәм»

В соответствии с планом основных организационных мероприятий МКУ «Отдел образования Исполнительного комитета Рыбно-Слободского муниципального района РТ» на 2016- 2017 учебный год приказываю:

1.Провести с 01.03.2019 г. по 14.03.2019 г муниципальную научно-практическую конференцию обучающихся «Әдәби мираслы Балык Бистәм» (далее Конференция);

2. 14 марта 2018 года организовать на базе МБОУ «Балыклы Чукаевская СОШ» очный (заключительный) этап Конференции;

3. Утвердить Положение о муниципальной научно-практической конференции обучающихся «Әдәби мираслы Балык Бистәм» (Приложение);

4. Утвердить состав организационного комитета Конференции:

- Садиков И.М., начальник МКУ «Отдел образования», председатель
- Залялова Р.Р., заместитель начальника МКУ «Отдел образования»
- Хисамова Л.Ф., методист МКУ «Отдел образования»
- Шамсевалиев Р. Ф. директор МБОУ «Балыклы- Чукаевская СОШ»

5. Методисту МКУ “Отдел образования Исполнительного комитета Рыбно-Слободского муниципального района РТ” Л.Ф. Хисамовой обеспечить координацию работы подведомственных учреждений;

6.Директору МБОУ «Балыклы Чукаевская СОШ» (Шамсевалиев Р.Ф.) обеспечить
выполнение необходимых организационных мероприятий по подготовке, проведению Конференции и размещению участников;

7. Руководителям общеобразовательных организаций организовать участие обучающихся
в Конференции и направить на Конференцию участников мероприятия и их руководителей;

8. Контроль за исполнением настоящего приказа возложить на заместителя начальника по учебно – методической работе Р.Р. Залялову.

Начальник: И.М.Садиков.

Утверждено приказом
МКУ «Отдел образования»
от « » октября _____2018 г.
№_____

Положение
о районной научно-практической конференции
обучающихся «Әдәби мираслы Балык Бистәм»
“Әдәби мираслы Балык Бистәм”- район
фәнни-гамәли конференциясе нигезләмәсе
(Танылган татар язучысы Вакыйф Нуруллин иҗаты буенча)

1.Гомуми мәгълүмат

Вакыйф Нуруллин (*Вакыйф Нурулла улы Нуруллин*) — танылган татар язучысы. Аның туган халкыбызга әдәби мирасының кыйммәте әйтеп бетергесез.

Районкүләм фәнни – гамәли конференция олы әдипнең иҗади колачын, милли сулышын, зирәк, фәлсәфи, тирән фикерләү осталыгын ачу һәм яшь буынга җиткерү максатыннан үткәрелә.

Әлеге нигезләмә “Әдәби мираслы Балык-Бистәм” фәнни-гамәли конференциясен үткәрү максатын, бурычларын билгели; оештыру, үткәрү, йомгаклау, җиңүчеләрне бүләкләү тәртибе белән таныштыра.

2. Максаты һәм бурычлары:

-Танылган татар язучысы Вакыйф Нуруллинның бай иҗатын, әдәби эшчәнлеген һәм мирасын барлау;

-телебезнең, милли мәдәниятебезнең рухи байлыгына укучыларны җәлеп итү;

-сәләтле һәм талантлы балаларны ачыкларга ярдәм итү, аларның үсеше өчен шартлар тудыру;

-укучыларда эзләнү эшчәнлеге аша фәнни фикерләү күнекмәләрен формалаштыру;

-укучыларда тарихи-мәдәни мирасыбызны өйрәнүгә карата кызыксыну арттыру;

-яшь буында милли хисләр тәрбияләү, милли үзаң формалаштыру;

3. Укуларны оештыручылар

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “ Балыклы-Чүкәй урта гомуми белем мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе.

4. Конференция кысаларында түбәндәге юнәлешләр:

-Вакыйф Нуруллин иҗатының үзенчәлеге; (8-11сыйныф укучылары өчен)

-Вакыйф Нуруллин- үзенчәлекле шәхес; (8-11сыйныф укучылары өчен)

-Сүзем якташым турында; (5-7, 8-9, 10-11сыйныф укучылары)

-Районның киләчәге - яшь буынның киләчәге ул (яшь язучылар, шагыйрьләр); (5-7, 8-9, 10-11сыйныф укучылары)
-”Туган ягым- яшел бишек” (укучылар тарафыннан иҗат ителгән кечкенә хикәяләр) (5-7, 8-9, 10-11сыйныф укучылары)

5. Бәяләү критерийлары

Фәнни эшләргә, чыгышларга түбәндәге критерийлардан чыгып бәя бирелә:

- укучының теманы ачып бирә алуы, композициянең тулылыгы;
- тема һәм проблеманы ачып бирә белү;
- эшнең максатын һәм бурычларын дөрес билгеләү, дәлилләнгән нәтиҗәләр ясау;
- авторның мөстәкыйльлек дәрәҗәсе;
- сайланган теманың актуальлеге;
- фәнни эштә логик эзлеклелек саклану;
- эшнең грамоталы, фәнни-эзләнү эшләренә булган таләпләргә туры килүе һәм китерелгән фактларның дөрес булуы;
- чыгыш ясаучының сөйләм осталыгы, аралашу культурасы;
- мөстәкыйль һәм эзлекле фикерләү;
- дәлилле һәм иҗади фикерләү сәләтенә ия булуы.

Иҗади эшләрнең сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсе, теленең образлылыгы, эчтәлек һәм форма берлеге, идея-эстетик кыйммәте исәпкә алыначак.

Күмәк эшләр кабул ителми.

Республикакүләм башка конкурсларда катнашкан, матбугатта басылган эшләр кабул ителми.

Конференциядә чыгыш ясау вакыты – 5-7 минут**.** Катнашучылар шушы вакыт эчендә, эчтәлекне ачып, төп фикерне әйтеп бирә белергә тиешләр (компьютер презентациясе хуплана).

Конференция 2019 нчы елның 14 мартында Балык Бистәсе муниципаль районы “Балыклы-Чүкәй урта гомуми белем мәктәбе” ГБМБУендә үткәрелә.

6. Конференцияне үткәрү һәм катнашу тәртибе

Конференция ике этапта үткәрелә.

1 тур- читтән торып - Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы укучылар 2019 нчы елның 1 нче мартына кадәр гариза, тезис һәм фәнни эшләрен Балык Бистәсе районы Балыклы-Чүкәй урта

гомуми белем бирү мәктәбенә түбәндәге электрон адрес буенча җибәрә ала: gulnaz-1605.1972@mail.ru

2 тур- Мәктәпкә килгән эшләр сайлап алына һәм 10 марттан соң катнашучыларга электрон почта аша чакыру җибәрелә.

Белешмәләр өчен телефоннар:

Конференция кураторлары :

Мустафина Венера Камилевна (тел. 89586268540)

Сафиуллина Зөлфирә Тәлгәтовна (тел.89196440819)

Фәнни-эзләнү эшләренең кәгазь варианты чыгыш ясар алдыннан экспертлар комиссиясенә тапшырыла.

Конференция башлану вакыты - 10.00 сәг., теркәлү – сәг. 8.30-9.30

7. Конференциядә катнашучылар

Укуларда гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 нче сыйныф укучылары катнаша ала.

8. Фәнни-эзләнү эшләренә таләпләр:

-Фәнни-эзләнү эше титул бите, эчтәлек, кереш, төп өлеш, йомгак, кулланылган әдәбият исемлеге, кушымта өлешләреннән тора.

-Титул битендә белем бирү учреждениесенең тулы исеме, районы, укучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, сыйныфы, тема һәм укытучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме языла.

-Кереш, йомгак, әдәбият исемлеге, төп өлешнең аерым бүлекләре яңа биттән башлана.

-Кулланылган әдәбият исемлеге яңа юлдан алфавит тәртибендә языла.

-Эш төзәтүләрсез А4 форматында шрифт Times Roman; зурлыгы– 14, кырлары: өстән,астан,сулдан-2см,уңнан-1,5см, юл араларындагы интервал -1,5см, компьютерда басылган булырга тиеш. Күләме 8-10 биттән артмаска тиеш. Эшләр татар телендә генә кабул ителә.

9. Конференцияне йомгаклау һәм нәтиҗә ясау.

Укучыларның фәнни һәм иҗади эшләренә, чыгышларына экспертлар комиссиясе бәяләү критерийларыннан чыгып бәя бирә. Эксперт комиссиясе утырышы үткәрелә һәм җиңүчеләр турында карар чыгарыла.

Җиңүчеләр һәм призлы урыннарга ия булучылар дипломнар белән бүләкләнә. Һәр катнашучыга электрон шәһадәтнамә җибәрелә.

«Әдәби мираслы Балык-Бистәм» – фәнни- гамәли конференциясендә катнашу өчен гариза

Укучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча)	
Сыйныфы	
Тәкъдим ителгән эшнен темасы	
Эшне җибәргән уку йортының исеме һәм электрон адресы	
Фәнни җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча)	
Вазыйфасы, укыта торган фәне	
Элемтә өчен телефон	
Чыгыш ясаганда кирәк булачак җиһазлар, техник чаралар	
Эшне тәкъдим итәргә теләгән секция (билгеләргә)	

(Оештыру комитеты эшне башка секциягә күчерү хокукын үз өстенә ала)